Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Городище торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елның 27 ноябре № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең Городище торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Городище торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 1000 сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли.
2. Алынган акчаларны торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга юнәлтергә (җимерелгән таш сатып алу, Полевая урамы буйлап, Городище авылындагы Колхозная урамы буйлап юл тутыру).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кармалы авыл җирлеге башлыгы Н.В. Мальцева